**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительного комитета Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**« 01 » август 2019 ел** **№ 245**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 22.03.2019 ел №67 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрү буенча Иҗтимагый совет турындагы Нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

"Мәдәният, сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә оешмалар һәм медик-социаль экспертиза федераль учреждениеләре тарафыннан хезмәт күрсәтүләр сыйфатын бәйсез бәяләүне уздыруны камилләштерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 05.12.2017 ел 392-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә иҗтимагый контроль нигезләре турында» 21.07. 2014 ел 212-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы белән, карар чыгара:

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 22.03.2019 ел №67 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрү буенча Иҗтимагый совет турындагы Нигезләмәне раслау хакында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 бүлекнең 3.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Иҗтимагый совет составына Россия Федерациясе һәм Россия Федерациясе субъектлары дәүләт вазыйфаларын, Россия Федерациясе һәм Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче затлар, муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затлар, шулай ук «Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы турында» 04.04.2005 ел 32-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы әгъзалары була алмый торган башка затлар керә алмый.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында»: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Җитәкче А.Х.Шәмсетдинов